# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2020 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 23 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Салкын-Чишмә торак пунктында Чапаев урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, вак таш салу, җәю, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 76 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 42 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
җыенда катнашкан 42 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пунктында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. "2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Салкын-Чишмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 400,00 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Салкын-Чишмә торак пунктында Чапаев урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзелеш, реконструкция, ремонт, вак таш салу, җәю, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми

сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев